Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР

18 декабрь, 2023 ел № 35

Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ошторма-Юмья выл Советы карар бирде:

1. Ошторма-Юмья авыл Советының 2018 елның 27 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (2018 елның 02 ноябрендәге 26 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 8 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 4 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 17 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы үзгәрешләр белән 2023 елның 30 октябрьдәге 30 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгына классы чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Ошторма-Юмья башлыгы С.В. Тимофеев

ОГРН 1021607752737
ИНН 1623001692